РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«31» март 2023 ел г. Альметьевск № 751

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль
районы Башкарма комитетының
«Җир кишәрлекләрен милеккә түләүсез алу
хокукына ия затлар буларак исәпкә кую буенча
муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ
регламентын раслау турында» 2021 елның
19 ноябрендәге 1641 номерлы карарына
үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» федераль законнар, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Җир кишәрлекләрен милеккә түләүсез алу хокукына ия затлар буларак исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 19 ноябрендәге 1641 номерлы карарына (Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 22 июлендәге 1547 номерлы, 2022 елның 28 сентябрендәге 2130 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Карарга 1 нче кушымтада:

- 2 бүлекнең 2.6.1 пунктындагы тугызынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9) фамилия-исем төркеменең, туган көненең, җенесенең һәм СНИЛСның туры килүен тикшерү – Россия Федерациясенең пенсия һәм социаль иминият фонды;»;

- 3 бүлекнең 3.3.1.1 пунктының унберенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Формалаштырылган гаризаны формаль-логик тикшерү орган (оешма) билгеләгән таләпләр нигезендә, мөрәҗәгать итүче һәр кырны электрон рәвештәге кырны тутыру процессында автомат рәвештә бердәм портал

23 156

Зак. № 305-2000

тарафыннан гамәлгә ашырыла. Бердәм портал тарафыннан тутырылган электрон рәвештәге кырның корректлы булмаса да, мөрәҗәгать итүче ачыкланган хатаның характеры һәм аны мәгълүмати хәбәр итү юлы белән сорауның электрон формасында бетерү тәртибе турында хәбәр итә.».

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары вазыйфаларын башкаручы А.А. Ямалетдиновка йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе А.М. Каюмов